**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2017 ел, 3 февраль № 53

г. Казань

«Дәүләт кадастр бәяләве үзәге» дәүләт бюджет учреждениесен төзү турында

«Дәүләт кадастр бәяләве турында» 2016 ел, 3 июль, ФЗ-237 нче Федераль закон нигезендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгының «Дәүләт кадастр бәяләве үзәге» дәүләт бюджет учреждениесен (алга таба – Учреждение) төзү турында тәкъдимен кабул итәргә.

2. Күчемсез мөлкәт объектларына дәүләт кадастр бәяләве үткәргәндә кадастр кыйммәтен билгеләүне Учреждение эшчәнлегенең төп максаты итеп билгеләргә.

3. Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгына:

Учреждениене гамәлгә куючы функцияләрен һәм вәкаләтләрен гамәлгә ашырырга;

10 көн эчендә Учреждение уставын расларга һәм аны законнарда билгеләнгән тәртиптә теркәүне тәэмин итәргә;

Учреждение уставын теркәгән көннән соң җиде көн эчендә Учреждение эшчәнлеген тәэмин итү өчен кирәкле Татарстан Республикасы дәүләт мөлкәтен Учреждениегә беркетергә, башка кирәкле оештыру чаралары үткәрергә;

Учреждение уставын теркәгән көннән соң җиде көн эчендә Казан шәһәре, Вишневский урамы, 26 нчы йорт адресы буенча урнашкан бинаның өченче катындагы урынны Учреждениегә түләүсез файдалануга бирергә;

ел саен Учреждение уставында каралган төп эшчәнлек төре нигезендә Учреждение өчен эшләр башкаруга дәүләт йөкләмәсен расларга.

4. Учреждение тарафыннан эшләр башкаруга дәүләт йөкләмәсен үтәүне финанслар белән тәэмин итү Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Дәүләт учреждениеләренә карата дәүләт хезмәтләре күрсәтүгә (эшләр башкаруга) дәүләт йөкләмәсен формалаштыру һәм дәүләт йөкләмәсе үтәлешен финанслар белән тәэмин итү тәртибе турында» 2015 ел, 31 декабрь, 1044 нче карарында билгеләнгән тәртиптә, тиешле финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турындагы Татарстан Республикасы законында Учреждениегә әлеге максатларга

күздә тотылган бюджет ассигнованиеләре чикләрендә гамәлгә ашырыла дип билгеләргә.

5. «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты каршындагы Татарстан Республикасының Икътисадый һәм социаль тикшеренүләр үзәге» дәүләт бюджет учреждениесенә, Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы белән берлектә, әлеге карарның 3 нче пунктындагы өченче – бишенче абзацларны үтәгәннән соң 30 көн эчендә Учреждение тарафыннан эшләр башкаруга норматив чыгымнарны раслау турында карар проектын эшләргә һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына раслауга кертергә.

6. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры И.Ш.Халиков

F:\KARAR\2017\53.docx